КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 11 март г.Казань № 177

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2018 ел, 19 сентябрь, 797 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан башкарыла торган донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эше күләмнәренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан донорлар канын һәм аның компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эшен башкаруга норматив чыгымнарны раслау турында» 2018 ел, 19 сентябрь, 797 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының медицина оешмалары тарафыннан башкарыла торган донорлар канын һәм аның

компонентларын хәзерләү, саклау, транспортта күчерү һәм аның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча дәүләт эше күләмнәренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» бүлегендә:

«кан донорларыннан компонентларга аертылмаган донорлар каны» юлының 5 графасындагы «18 917,4» саннарын «19 394,67» саннарына алыштырырга;

«автоматик аферез ысулы белән компонентларга аертылмаган донорлар каны (плазмоферез ысулы белән яңа туңдырылган плазма хәзерләү өчен)» юлының 5 графасындагы «12 932,3» саннарын «12 491,4» саннарына алыштырырга;

«тромбоцитоферез ысулы белән компонентларга аертылмаган донорлар каны (плазмоферез ысулы белән яңа туңдырылган плазма хәзерләү өчен)» юлының 5 графасындагы «4 479,0» саннарын «4 962,5» саннарына алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин